| «Рассмотрена»<br><br>Руководитель ШМО<br><br>_________ /______________ /<br><br>Протокол №____<br><br>от «___» _________ 20_ | «Согласована»<br><br>Заместитель директора по УВР МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br><br>_________ /______________ /<br><br>«___» _________ 20__г. | «Утверждаю»<br><br>Директор МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br><br>________ /______________ /<br><br>Приказ № ______<br><br>от «___» _________ 20__г. |
|---|---|---|

**Рабочая программа**
**по литературному чтению на родном (татарском) языке для 4 класса**

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Старомокшинская средняя общеобразовательная школа
имени В.Ф.Тарасова» Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан

Мирзяновой Назии Сантбурхановны,
учителя татарского языка и литературы
первой квалификационной категории.

Рассмотрена и принята на заседании
педагогического совета.
Протокол № ___от _______ августа

Срок реализации: 2018-2019 учебный год

**Аңлатма язуы**

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

- Положением о рабочей программе учебных предметов , курсов, в соответствии с ФГОС МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» , утвержденным приказом от 29.08.2018 г. № 175

-Учебным планом МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» на 2018-2019 учебный год , утвержденным приказом от 29.08.2018 г № 168, календарным учебным графиком , утвержденным приказом от 29.08.2018 г №171

- Основной образовательной программы начального общего образования МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова»

Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова. Әдәби уку (2 кисәктән). Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 4нче сыйныф ( татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016., Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслек.

**Эш программасының эчтәлеге**

Эш программасының һәм белем бирүнең **максаты:**

Аралашу компетенциясе ул — башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ. б.

Этнокультура өлкәсенә караган компетенция, ягъни әдәбиятны милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул — укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

Рус мәктәбендә татар әдәбиятын укытуның **төп бурычлары** түбәндәгеләр:

-укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту, үз милләтеңә һәм аның әдәбиятына мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

-татар әдәбияты, аның аеруча күренекле вәкилләре турында беренчел күзаллау булдыру;

-әдәби әсәрне тыңлап һәм укып аңлау күнекмәләре булдыру;

-текст белән танышу, эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру, аны камилләштерә бару;

-телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру;

-укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү;

-әдәби текстларны дөрес, тиз һәм тора-бара сәнгатьле итеп укуларына ирешү;

-мөстәкыйль рәвештә әдәби әсәрләрне укырга һәм үзләштерергә күнекиерү, белемгә омтылыш, китапка карата кызыксыну тәрбияләү;

-татар әдәбияты белән бергә башка халыкларның сүз сәнгатенә дә кызыксыну тәрбияләү;

-укучыларның мантыйклы һәм иҗади фикер йөртүен, затлы зәвыгын үстерү;

-әдәби әсәрләр ярдәмендә үз-үзеңне әдәпле тотуга ихтыяҗ тәрбияләү;

-дөрес, бәйләнешле итеп телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү һ.б.

Татар әдәбияты дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычны да үтәү мөһим. Телебезнең тәрбияви мөмкинлекләрен ачуда укуга карата кызыксыну уяту зур әһәмияткә ия, чөнки ана телен өйрәнү теләге укучының эчке ихтыяҗына әверелә.

Программа укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү бурычын да куя. Балалар, ана телендә аралашканда, фикерләрен ачык, аңлаешлы, эзлекле, стилистик яктан дөрес, төгәл итеп адресатка җиткерә белергә тиеш. Бу бер үк вакытта сөйләм теленә дә, язма телгә дә карый, ягъни укучыларда ана телендә дөрес, матур итеп сөйләү һәм язу күнекмәләре тәрбияләү максаты куела.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының күбрәк рус телендә аралашуларын һәм фәннәрнең рус телендә үзләштерелүен истә тотып, темаларны үткәндә, аның рус телендәге үзенчәлеген (охшаш яки аермалы якларын) кыскача билгеләп бару зарур.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү , сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан, сочинение яздырыла.

4 нче сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән программа түбәндәге **максатларны** куя:

- укучыларда ана телен өйрәнүгә омтылыш, эзләнүгә теләк уяту, милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү;

- сөйләм һәм аралашу өлкәсенә караган мәгълүматлылык булдыру;

- план төзеп сөйләү, сораулар бирә белү, рәсем буенча хикәя төзү.

**Төп бурычлар:**

- уку күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;

- укуга кызыксыну, китапка хөрмәт тәрбияләү, мәктәпкә, белем алуга уңай караш уяту;

- матур әдәбият, аның авторы, әсәрнең жанры, персонажы турында күзаллау булдыру;

- бәйләнешле телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү;

- әдәби әсәрләр йогынтысында табигатькә сакчыл караш, үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру;

- укучыларның әсәрне эмоциональ кабул итүенә ирешү; хисләрне әхлакый, рухи матурлык тойгылары белән баету;

- әдәби әсәрләрне укыганда, балаларның акылын, ихтыярын, хисләрен һәм рухи ихтыяҗларын үстерү.

Татар халкының бай әдәби мирасын үзләштерү, халыкның үткәнен белү яшь буынга аң-белем һәм тәрбия бирү, аларның милли үзаңын үстерүдә мөһим роль уйный.

Әдәби уку программасына текстларның күбесе балалар әдәбиятыннан һәм әдәби әсәрләрдән сайланып, табигать, кешенең табигатькә мөнәсәбәте, аның табигатьне саклаудагы роле,якын туганнар, чит кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бүгенге заман проблемаларына туры килә. Ел фасылларына багышланган шигырь һәм хикәяләр балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, матурлыкны күрә белү сәләтен үстерергә ярдәм итә. Шактый текст *фольклордан* алына. Эчтәлеге укучыларга якын булган әкиятләр укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүгә өлеш кертә.

Программада дәресләр “Уку һәм текстны өйрәнү”, “Сыйныфтан тыш уку”, “Бәйләнешле сөйләм үстерү” тематикасы буенча планлаштырылды. Сөйләшү тематикасы үтелгән материалдан, аңа бәйле лексик-фразеологик минимумнан чыгып билгеләнде. Укучыларда әдәпле сөйләм формалаштыру максатын күздә тотып, ул һәр сыйныфта да кертелгән. Безнең максат – аны сыйныф саен тирәнәйтә бару.

**Программаның эчтәлеге**

**1. Әдәби әсәр белән эшләү:**
- текстның темасын аңлата белү;
- текстны вакыйгасы буенча өлешләргә тарката белү;
- сорау куя белү;
- укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча эчтәлеген сөйли белү;
- укытучы ярдәмендә текстның төп фикерен билгели белү.

**2. Сөйләм телен үстерү:**
- үзләштергән материалга нигезләнеп, ирекле сөйләшү-диалог оештыру;
- яшь үзенчәлегенә туры килердәй текст сайлау;
- бирелгән план буенча эчтәлекне сөйләү;
- иҗади эшләргә өйрәнү-хикәя, әкиятләрне дәвам итү, әкиятләр, табышмаклар уйлау;
- шигырьләр ятлау.

**3. Әдәбият белемен өйрәнүгә әзерлек:**
- сүз сәнгатенең бер төре буларак матур әдәбият белән таныштыра башлау;
- әкиятләрнең төп фикере,кызыклы сюжеты һәм композициясе;
- әдәби әсәрләрнең темасын, идеясен билгеләргә өйрәтү;
- табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр,башваткычлар;
- төрле сурәтләү чаралары белән таныштыру.

**4. Уку техникасы:**
- аңлап, йөгерек, сәнгатьле уку;

- кычкырып уку тизлеге – 70 (авыр үзләштерүчеләр өчен), 90-110 (яхшы үзләштерүчеләр өчен) сүздән ким булмау;
- эчтән шома уку күнекмәләрен формалаштыру;
- укыганны аңлап сөйләргә өйрәтү.

**5. Китап уку белән кызыксыну дәрәҗәсе:**

- татар һәм башка милләт язучыларының әкиятләре;
- татар классик язучыларының балалар укырга тиешле әсәрләре;
- вакытлы матбугат:балалар өчен газета, журналлар белән таныша башлау.

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

**Гомуми белем бирү осталыгына таләпләр:**

- укылган текстка сорау куя белү;
- әсәрне яки аерым өлешне төгәл итеп сөйләү;
- бирелгән план буенча эчтәлек сөйләү;
- иҗади эшләү: хикәя,әкият, табышмаклар иҗат итү, аларны анализларга, фикереңне белдерергә өйрәтү.

**Предмет буенча укучылар белергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре:**

- шигырьләрне яттан сөйли белү; анализлауның беренчел күнекмәләренә төшендерү;
- халык аваз иҗатын әдәби әсәрдән аера белергә, аларга дөрес бәяләмә бирергә өйрәтү;
- әдәби һәм сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен булдыру;
- тропларның еш кулланыла торганнарын (метафора, эпитет, аллегория, чагыштыру һ.б.) аера белергә, әдәби әсәрдән табарга һәм сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы**

**Коммуникатив компетенция**.Сөйләм.Телдән һәм язма сөйләм.Диалогик һәм монологик сөйләм.Матур әдәбият теле.

Телдән һәм язма сөйләмне аеру.Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү, аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Сөйләм эшчәнлеге төрләрен(тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.Укуның төрле төрләрен(танышу,өйрәнү һ.б.) үзләштерү.Уку китаплары белән эшләү алымнарын үзләштерү.

Уку темаларына бәйле булган монологик һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.Текстның эчтәлеген кыскача, тулы яки сайлап алып сөйләү. Сочинениеләр язу.

## УКЫТУНЫҢ ГОМУМИ, ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

— сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
— өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;

— әдипләрнең биографик белешмәләре белән танышу;
— өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
— әдәби текстны кабул итү;
— әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару;
— әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
— укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
— геройларга характеристика бирү;
— әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
— укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
— әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
— кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
— өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
— укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
— татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**

— шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
— активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
— үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
— милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.

**Метапредмет нәтиҗәләре**

Метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ).

**Регулятив УУГ (РУУГ):**

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

**Танып белү УУГ (ТБУУГ):**

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү (төп текст, астөшермә һ.б.), өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;
- укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап);

- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау (тулы текст, өзек, иллюстрация, схема);
— бер мәгълүматны икенче төрле итеп үзгәртә алу (план төзү, таблица, схема);
— укылган әсәрнең эчтәлеген (яки ишеткәнне), текстка якын итеп, кыскача сайлап сөйли белү;
— әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;
— әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стилен җиткерү;
— татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән таныштыру;
— сүзлекләр, белешмә материаллардан файдалану;
— бәхәсләшү, үз фикерен дәлилләү, анализ ясау, йомгаклау;
— әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

**Коммуникатив УУГ (КУУГ):**

— төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
— үз фикерен тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү;
— бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
— күмәк эш вакытында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;
— укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә алу;
— үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;
— коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
— үз фикерләрен телдән һәм язма формада җиткерә белү;
— башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;
— иптәшләре каршында төрле темаларга чыгыш ясау;
— бергәләп эшләгәндә бердәм карар кабул итә алу;
— текст буенча сораулар куя белү.

**Предмет нәтиҗәләре**

**Танып-белү өлкәсендә:**

— төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
— сәнгатьле уку;
— шигъри кабатлап сөйләүнең төрле төрләреннән файдалану (**тулы** итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән);
— текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү; әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;
— план төзү;

— әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, тулы яки мини -сочинение язу;

— укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру;

— өстәмә белем чыганакларыннан язучыларның тормышы һәм иҗаты турында белү;

— татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре,аларның иҗаты турында белү;

**Әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә:**

– татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыру;

– татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү;

– өйрәнелгән әдәби әсәрләргә аерым очракларда үзгәреш кертә белү;

– автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау.

**Коммуникатив өлкәдә:**

— төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;

— чәчмә әсәрләрне яки өзекләрне татар теленең әдәби чараларын һәм цитаталарын кулланып сөйли белү, укыган яки ишеткән текст буенча сорауларга җавап бирә алу, телдән төрле типтагы монолог, диалоглар төзү, әңгәмә кору;

**Эстетик өлкәдә:**

— әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әсәрләрдән рухи тәм табу;

— сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау.

**Эчтәлек:**

**Халык сүзе алтындыр, аңлаганга акылдыр (9 сәгать)**
*“Җил арба” (Татар халык әкияте)*
*“Җил иясе”(Миф)*
*“Тургай һәм кояш” (Миф)*
*“Сак-Сок” бәете*
*Фатих Әмирхан “Ай өстендә Зөһрә кыз”*
*Габдулла Тукай “Яшь агач”*
*Иван Крылов “Карга белән Төлке”*
*Мәҗит Гафури “Чикерткә белән Кырмыска”*
*Мәҗит Гафури “Тавык белән Үрдәк”*
*Әхмәт Исхак “Карт Имән белән яшь егет”*
**Язучылар һәм рәссамнар иҗатында табигать (7 сәгать)**
*Габдулла Тукай “Ай һәм кояш”*
*Габдулла Тукай “Фатыйма белән Сандугач”*
*Габдулла Тукай “Шүрәле”*
*Мәҗит Гафури “Болын”*
*Муса Җәлил “Яңгыр”*
*Муса Җәлил “Чишмә”*
*Абдулла Алиш “Койрыклар”*
*Нәби Дәүли “Бала болыт”*
*Рәшит Бәшәр “Сандугачлы Ак инеш”*
*Гәрәфи Хәсәнов “Кышкы урман”*

*Фәнис Яруллин “Иң бәхетле төн”*
*Сания Әхмәтҗанова “Саклыйк, әйдә, Җир-ананы”*
**Балачак әдипләре (5 сәгать)**
*Шәүкәт Галиев “Камырша”*
*Шәүкәт Галиев “Күршеләрнең алмасы”*
*Шәүкәт Галиев “Минем абый шигырь ятлый”*
*Роберт Миңнуллин “Әни, мин көчек күрдем”*
*Роберт Миңнуллин “Спортның яңа төре”*
*Хәкимҗан Халиков “Дәү әти”*
*Хәкимҗан Халиков “Вакыты тар”*
*Хәкимҗан Халиков “Чыпчык баласы Чырчыр турында әкият”*
*Сынлы сәнгать музеенда. Харис Якупов “Аналар җәе” картинасы*
*Хәкимҗан Халиков “Нинди кош?”*
*Фәнис Яруллин “Юылмас хурлык”*

**Яхшылык эшләргә ашыгыйк...(5 сәгать)**
*Роза Хафизова “Күгәрчен һәм малай”*
*Сәрвәр Әдһәмова “Дуслар”*
*Дәрҗия Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар”*
*Михаил Зощенко “Мескен Федя”*
**Бәхетле балачак (3 сәгать)**
*Нәбирә Гыйматдинова “Сертотмас кәҗә”*
*Юрий Ермолаев “Сәгать ярдәм итте”*
**Серле дөнья, могҗизалы дөнья (5 сәгать)**
*Ганс Христиан Андерсен “Чыдам кургашын солдат”*
*Джонатан Свифт “Гулливер сәяхәте”*
*Ләбиб Лерон “Шүрәле малае”*
Әдәби пропедевтика
Әдәби төшенчәләрне (әдәбият, фольклор, әдәби әсәр, әдәби иҗат) үзләштерү.
Әдәби жанрлар: бәет, мәсәл, риваять, хикәя, шигырь, әкият-пьеса, очерк, фәнни-популяр мәкалә, фәнни-әдәби әсәр.
Әсәр темасы, идеясе: әдәби герой, портрет, автор бәяләмәсе, сюжет, композиция.
Тел-сурәтләү чаралары: эпитет, чагыштыру, сынландыру, гипербола.
Автор уен белдерү чарасы буларак юмор һәм сатира.
Фантастика һәм чынбарлык.
Иҗади эшчәнлек
Таныш сюжетны «язып бетерү», «дәлилләү». Халык авыз иҗаты үрнәгендә табышмак, такмак, әкият, әйтем уйлау.
Укылган китапларга бәяләмә, аннотация язу, китапның каталог карточкасын төзү.
Зур булмаган әсәр сюжетларын сәхнәләштерү, сәхнәләштергән уеннарда, диалогларда катнашу.

Укыту - тематик планы

| Бүлек | Укучылар эшчәнлеге | Сәгать саны |
|---|---|---|
| Халык сүзе алтындыр, аңлаганга акылдыр | Дәреслекнең беренче кисәге белән танышу. Халык авыз иҗаты әсәрләре темасын искә төшерү. Табышмаклар, аларның төрләрен искә төшерү. Әкиятләр, аларга хас үзенчәлекләрне искә төшерү һәм ныгыту. Әкият геройларына характеристика бирү. Әкиятләрдән эпитет һәм сынландыруларны табу. Әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү. Миф төшенчәсен аңлату. Портрет төшенчәсен | 7 |

| | | |
|---|---|---|
| | аңлату (Ф.Әмирхан. “Ай өстендә Зөһрә кыз”). Әкиятләрнең рәсемле планын төзү һәм план буенча сөйләргә өйрәнү. Бәет төшенчәсен аңлату. Дәреслектәге һәм эш дәфтәрендәге биремнәрне үтәү. | |
| Язучылар һәм рәссамнар иҗатында табигать | Г.Тукай, М.Гафури, М.Җәлил ,А.Алиш, Н.Дәүли, Р.Бәшәр, Г.Хәсәнов һәм Ф.Яруллин иҗаты белән танышу. Алар иҗатыннан бирелгән үрнәкләрне уку һәм эчтәлеген сөйли белү. Халык авыз иҗаты һәм Тукай иҗатын чагыштыру, уртак якларын табу. Пейзаж төшенчәсен үзләштерү. Б.Әлменовның «Шүрәле» картинасы буенча эш. “Без табигать балалары» темасы буенча проект эше. Сорау һәм биремнәрне үтәү. | 9 |
| Балачак әдипләре | Дәреслекнең икенче кисәге белән танышу.Иллюстрация буенча әңгәмә. Текстларны уку һәм аларга анализ ясау: жанр төрен билгеләү, геройларга характеристика бирү, геройга карата автор мөнәсәбәтен ачыклау һәм аңа карата үз мөнәсәбәтеңне җиткерү. Гипербола төшенчәсен үзләштерү. Х.Якуповның “Аналар җәе” картинасы буенча эш. Сәхнә әсәре турында белешмә. Х.Халиковның "Нинди“кош” әсәрен рольләргә бүлеп уку. Дәреслектәге һәм эш дәфтәрендәге сорау һәм биремнәрне үтәү. | 5 |
| Яхшылык эшләргә ашыгыйк | Текстларны уку һәм эчтәлеген аңлау, аларның төп уен һәм жанрын билгеләү. Геройларның эш-гамәлләрен бәяләү, геройга карата булган мөнәсәбәтеңне аңлату. Текстка план төзү һәм план буенча эчтәлекне кыскартып сөйли белү. Эпитет, чагыштыру, сынландыруларны табу.Дәреслектәге һәм эш дәфтәрендәге сорау һәм биремнәрне үтәү. | 5 |
| Бәхетле балачак | Дәреслектә бирелгән текстларны уку һәм эчтәлеген аңлау, аларның төп уен һәм жанрын билгеләү. Эчтәлекне кыскартып сөйләү. Үз тәҗрибәңнән чыгып, кызыклы вакыйга турында сөйләү. Дәреслектәге һәм эш дәфтәрендәге сорау һәм биремнәрне үтәү. | 3 |
| Серле дөнья, могҗизалы дөнья | Текстларны йөгерек, дөрес итеп уку һәм эчтәлеген аңлау, аларның темасын, төп уен һәм жанрын билгеләү. Әкиятләрне өлешләргә бүлү, һәр өлешкә исем уйлау һәм аларны кыскартып сөйли белү. Гулливерның портретын сөрәтләү. Гипербола төшенчәсен үзләштерү. Геройларга характеристика бирү. Дәреслектәге һәм эш дәфтәрендәге сорау һәм биремнәрне үтәү. | 5 |
| Барысы | | 34 |

**4 нче сыйныф татар төркеме өчен әдәби укудан тематик план**

| № | Дәрес темасы | Дәрес саны |
|---|---|---|
| **Халык сүзе алтындыр, аңлаганга акылдыр ( 7сәг.)** | | |
| 1. | Халык авыз иҗаты әсәрләре. “Җил арба”әкияте. | 1 |
| 2. | Мифлар. “Җил иясе”. “Тургай һәм Кояш”. | 1 |
| 3. | Ф.Әмирхан “Ай өстендә Зөһрә кыз” | 1 |
| 4. | Бәетләр. “Сак – Сок”. | 1 |
| 5. | М И.Крылов. «Карга белән төлке» (Габдулла Шамуковтәрҗемәсендә). | 1 |
| 6. | Гафури “Чикерткә белән Кырмыска”. “Тавык белән үрдәк”. | 1 |
| 7. | Г.Тукай “Яшь агач”. Ә.Исхак “Карт имән белән яшь егет”. | 1 |
| **Язучылар һәм язучылар иҗатында табигать (9сәг.)** | | |
| 8. | Габдулла Тукай “Фатыйма белән сандугач”. “Ай һәм кояш”. | 1 |
| 9. | Габдулла Тукай “Шүрәле”. | 1 |
| 10. | М.Гафури “Болын”. Муса Җәлил “Яңгыр”, “Чишмә”. | 1 |
| 11. | А.Алиш “Койрыклар”. | 1 |
| 12. | А.Алиш “Кемгә кирәк, кемгә кирәкми”. Н.Дәүли “Бала болыт” | 1 |
| 13. | Р.Бәшәр “Сандугачлы Ак инеш” . Гарәфи Хәсәнов “Кышкы урман” | 1 |
| 14. | Фәнис Яруллин “Иң бәхетле төн”, “Сания”. | 1 |
| 15. | С. Әхмәтҗанова “Саклыйк, әйдә, җир-ананы”. Кабатлау. | 1 |
| **Балачак әдипләре (5 сәг.)** | | |
| 16. | Шәүкәт Галиев “Камырша”, “Күршеләрнең алмасы”, “Минем абый шигырь ятлый”. | 1 |
| 17. | Роберт Миңнуллин “Әни, мин көчек күрдем”. Ш.Галиев һәм Р.Миңнуллиннарның иҗатын кабатлау. | 1 |
| 18. | Х.Халиков “Дәү әти”, “Вакыты тар”, Х.Халиков“Чыпчык баласы Чырчыр | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | турында әкият”. Фәрит Якуповның “Аналар җәе” рәсеме. | |
| 19. | Хакимҗан Халиков “Нинди кош?” | 1 |
| 20. | Ф.Яруллин “Ап-ак иткән”, “Бияләй”, “Юылмас хурлык”. Х.Халиков һәм Ф.Яруллиннарның иҗатларына күзәтү. | 1 |
| **Яхшылык эшләргә ашыгыйк (5 сәг.)** | | |
| 21. | Роза Хафизова “Күгәрчен һәм малай”. | 1 |
| 22. | С.Әдһәмова “Дуслар”. | 1 |
| 23. | Әхсән Баян “Эт янында тиеннәр” | 1 |
| 24. | Дәрҗия Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар” | 1 |
| 25. | Михаил Зощенко “Мескен Федя” | 1 |
| 26. | Резеда Вәлиева “Җиңү көнендә”. Искәндәр Рәфыйковның “Сугыш еллары” рәсеме. | 1 |
| **Бәхетле балачак (3сәг.)** | | |
| 27. | Нәбирә Гыйматдинова “Сертотмас кәҗә”. | 1 |
| 28. | Виктор Голявкин “Әллә каян күренеп тора”. | 1 |
| 29. | Юрий Ермолаев “Сәгать ярдәм итте”. | 1 |
| **Серле дөнья, могҗизалы дөнья (5сәг.)** | | |
| 30. | Г.Х.Андерсен “Чыдам кургашын солдат”. | 1 |
| 31. | Джонатан Свифт “Гулливер сәяхәте”. | 1 |
| 32. | Ләбиб Лерон “Шүрәле малае”. | 1 |
| 33. | Зиннур Хөснияр “Шүрәле җыры”. | 1 |
| 34. | Язгы табигатькә сәяхәт. | 1 |

*Кушымта*

**4 нче сыйныф татар төркеме өчен әдәби укудан календарь- тематик план**

| № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| **1 нче чирек – 9 сәг.** | **Халык сүзе алтындыр, аңлаганга акылдыр (7 сәг.)** | | | |
| 1. | Халык авыз иҗаты әсәрләре. “Җил арба”әкияте. | 1 | 07.0 9 | |
| 2. | Мифлар. “Җил иясе”. “Тургай һәм Кояш”. | | 14. 09 | |
| 3. | Ф.Әмирхан “Ай өстендә Зөһрә кыз” | 1 | 21.09 | |
| 4. | Бәетләр. “Сак – Сок”. | 1 | 28.09 | |
| 5. | М И.Крылов. «Карга белән төлке» (Габдулла Шамуковтәрҗемәсендә). | 1 | 05.10 | |
| 6. | Гафури “Чикерткә белән Кырмыска”. “Тавык белән үрдәк”. | 1 | 12.10 | |
| 7. | Г.Тукай “Яшь агач”. Ә.Исхак “Карт имән белән яшь егет”. | 1 | 19.10 | |
| **Язучылар һәм язучылар иҗатында табигать (9сәг.)** | | | | |
| 8. | Габдулла Тукай “Фатыйма белән сандугач”. “Ай һәм кояш”. | 1 | 26.10 | |
| 9. | Габдулла Тукай “Шүрәле”. | 1 | 09.11 | |
| 10. | М.Гафури “Болын”. Муса Җәлил “Яңгыр”.”Чишмә”. | 1 | 16.11 | |
| 11. | А.Алиш “Койрыклар” | 1 | 23.11 | |
| 12. | А.Алиш “Кемгә кирәк, кемгә кирәкми”. Н.Дәүли “Бала болыт” | 1 | 30.11 | |
| 13. | Р.Бәшәр “Сандугачлы Ак инеш” Гарәфи Хәсәнов “Кышкы урман” | 1 | 07.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14. | Фәнис Яруллин “Иң бәхетле төн”, “Сания” | 1 | 14.07 | |
| 15. | С. Әхмәтҗанова “Саклыйк, әйдә, җир-ананы”. Кабатлау. | | 21. 12 | |
| **Балачак әдипләре (5 сәг.)** | | | | |
| 16. | Шәүкәт Галиев “Камырша”, “Күршеләрнең алмасы”, “Минем абый шигырь ятлый”. | 1 | 11.01 | |
| 17. | Роберт Миңнуллин “Әни, мин көчек күрдем”. Ш.Галиев һәм Р.Миңнуллиннарның иҗатын кабатлау. | 1 | 18.01 | |
| 18. | Х.Халиков “Дәү әти”, “Вакыты тар”, Х.Халиков“Чыпчык баласы Чырчыр турында әкият”. Фәрит Якуповның “Аналар җәе” рәсеме. | 1 | 25.01 | |
| 19. | Хакимҗан Халиков “Нинди кош?” | 1 | 01.02 | |
| 20. | Ф.Яруллин “Ап-ак иткән”, “Бияләй”, “Юылмас хурлык”. Х.Халиков һәм Ф.Яруллиннарның иҗатларына күзәтү. | 1 | 08.02 | |
| **Яхшылык эшләргә ашыгыйк (5 сәг.)** | | | | |
| 21. | Роза Хафизова “Күгәрчен һәм малай”. | 1 | 15.02 | |
| 22. | С.Әдһәмова “Дуслар”. | 1 | 22.02 | |
| 23. | Әхсән Баян “Эт янында тиеннәр” | 1 | 01.03 | |
| 24. | Дәрҗия Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар” | 1 | 15.03 | |
| 25. | Михаил Зощенко “Мескен Федя” | 1 | 22.03 | |
| 26. | Резеда Вәлиева “Җиңү көнендә”. Искәндәр Рәфыйковның “Сугыш еллары” рәсеме. | 1 | 05.04 | |
| **Бәхетле балачак (3сәг.)** | | | | |
| 27. | Нәбирә Гыйматдинова “Сертотмас кәҗә”. | 1 | 12.04 | |
| 28. | Виктор Голявкин “Әллә каян күренеп тора”. | 1 | 19.04 | |
| 29. | Юрий Ермолаев “Сәгать ярдәм итте”. | 1 | 26.04 | |
| **Серле дөнья, могҗизалы дөнья (5сәг.)** | | | | |
| 30. | Г.Х.Андерсен “Чыдам кургашын солдат”. | 1 | 03.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31. | Джонатан Свифт “Гулливер сәяхәте”. | 1 | 10.05 | |
| 32. | Ләбиб Лерон “Шүрәле малае”. | 1 | 17.05 | |
| 33. | Зиннур Хөснияр “Шүрәле җыры”. | 1 | 17.05 | |
| 34. | Язгы табигатькә сәяхәт. | 1 | 24.05 | |